ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

20 май 2021ел № 3380

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә иҗтимагый-сәяси, массакүләм мәдәни һәм массакүләм спорт бәйрәм чаралары үткәргәндә сәүдә оештыру турында

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә иҗтимагый-сәяси, массакүләм мәдәни һәм массакүләм спорт бәйрәм чаралары үткәрү чорында халыкны сәүдә һәм җәмәгать туклануы хезмәтләре белән тәэмин итү өчен шартлар тудыру максатларында, «Россия Федерациясендә сәүдә эшчәнлеген дәүләти җайга салу нигезләре турында» 2009 елның 28 декабрендәге 381-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон һәм шәһәр Уставының 42 статьясы нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә иҗтимагый-сәяси, массакүләм мәдәни һәм массакүләм спорт бәйрәм чаралары үткәргәндә сәүдә оештыру турында нигезләмәне кушымтада каралганча расларга.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Н.А. Кропотовага йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2021 елның 20 маендагы
3380 номерлы карарына
кушымта

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә иҗтимагый-сәяси, массакүләм мәдәни һәм массакүләм спорт бәйрәм чаралары үткәргәндә сәүдә оештыру турында нигезләмә

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1. Әлеге Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә иҗтимагый-сәяси, массакүләм мәдәни һәм массакүләм спорт бәйрәм чаралары үткәргәндә сәүдә оештыру турындагы нигезләмә (алга таба – Нигезләмә) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә иҗтимагый-сәяси, массакүләм мәдәни һәм массакүләм спорт бәйрәм чаралары үткәргәндә сәүдәне гамәлгә ашырганда, халыкка җәмәгать туклануы һәм күңел ачу хезмәтләре күрсәткәндә, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты һәм хуҗалык итүче субъектлар (юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр, «Һөнәри керемгә салым» махсус салым режимын кулланучы физик затлар) арасында барлыкка килә торган мөнәсәбәтләрне, шулай ук стационар булмаган сәүдә, җәмәгать туклануы объектларын, күңел ачу аттракционнарын урнаштыру тәртибен һәм мондый чаралар (алга таба – күчмә сәүдә) үткәргәндә хуҗалык итүче субъектларга карата куела торган таләпләрне җайга сала.

2. Күчмә сәүдә дигәндә Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә иҗтимагый-сәяси, массакүләм–мәдәни һәм массакүләм-спорт бәйрәм чаралары (алга таба – шәһәр чаралары) үткәргәндә хуҗалык итүче субъектлар тарафыннан халыкка җәмәгать туклануы хезмәтләре, күңел ачу хезмәтләре күрсәтү (аттракционнар, батутлар, атларда һәм пониларда йөрү һ.б.) һәм товарлар сату аңлашыла.

3. Күчмә сәүдәдә катнашучыларга товарлар сату һәм хезмәтләр күрсәтү эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен сәүдә урыннары түләүсез бирелә.

## 2. Күчмә сәүдә объектларын урнаштыру һәм аларның эшен оештыру тәртибе

4. Күчмә сәүдәне үткәрү датасы, урыны, оештыру комитеты составы һәм шәһәр чарасын әзерләү һәм үткәрү планы Башкарма комитетның шәһәр чарасын оештыру һәм үткәрү турындагы карары белән билгеләнә.

5. Күчмә сәүдәне оештыру буенча чараларны Башкарма комитетның икътисадый үсеш һәм эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү идарәсе гамәлгә ашыра.

6. Башкарма комитетның икътисадый үсеш һәм эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү идарәсе әлеге Нигезләмәнең 1 нче кушымтасында каралган форма буенча шәһәр территориясендә күчмә сәүдә оештыру турында хәбәр әзерләүне гамәлгә ашыра (алга таба – Хәбәр).

7. Тиешле тәртиптә теркәлгән, күчмә сәүдәдә катнашырга теләүче оешмалар, шәхси эшмәкәрләр, «Һөнәри керемгә салым» махсус салым режимын кулланучы физик затлар (алга таба – Гариза бирүчеләр) Яр Чаллы шәһәре Башкарма комитетына kancel.chelny@tatar.ru электрон адресына, түбәндәге документларны теркәп, Хәбәргә

кушымтада каралган форма буенча Башкарма комитет Җитәкчесе исеменә күчмә сәүдәдә катнашуга заявка җибәрәләр:

- юридик затлар өчен – юридик зат турындагы мәгълүматларны бердәм дәүләт юридик затлар реестрына кертүне раслый торган документ күчермәсе;

- шәхси эшмәкәләр өчен – шәхси эшмәкәр турындагы мәгълүматларны бердәм дәүләт шәхси эшмәкәрләр реестрына кертүне раслый торган документ һәм салым органында исәпкә кую турында таныклык күчермәсе;

- «Һөнәри керемгә салым» махсус салым режимын кулланучы физик затлар өчен – физик затны һөнәри керемгә салым түләүче сыйфатында исәпкә кую турында белешмә күчермәсе.

8. Күчмә сәүдәдә катнашуга заявкалар сәүдәне оештыру турында хәбәрдә күрсәтелгән, «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында, «Интернет» челтәрендә Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында басылып чыккан хәбәрдә күрсәтелгән срокларда кабул ителә.

9. Заявкалар күчмә сәүдәдә катнашуга заявкаларны карап тикшерү буенча комиссия тарафыннан карап тикшерелә (әлеге Нигезләмәгә 2 нче кушымта).

Заявкаларны карап тикшерү нәтиҗәләре буенча, комиссия әлеге нигезләмәгә 3 нче кушымта нигезендә, сәүдә урыны бирү һәм күчмә сәүдәдә катнашучылар исемлегенә кертү турында яисә сәүдә урыны бирүдән баш тарту турында карар кабул итә.

10. Сәүдә урыны бирүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

1) әлеге Нигезләмәнең 7 пунктында күрсәтелгән документлар булмау;

2) гариза бирүче тарафыннан дөрес булмаган мәгълүмат бирелү;

3) мондый чаралар үткәргәндә хуҗалык итүче субъект тарафыннан гамәлдәге законнарны бозу турында рәсми мәгълүмат булу;

4) тыелган товарлар сату һәм тыелган хезмәтләр күрсәтү күздә тотыла.

11. Башкарма комитет Җитәкчесе тарафыннан расланган күчмә сәүдәдә катнашучылар исемлеге Яр Чаллы шәһәре буенча Россия Эчке эшләр министрлыгының идарәсенә һәм Татарстан Республикасы буенча Россия кулланучылар күзәтчелеге идарәсенең Яр Чаллы шәһәрендәге, Актаныш, Тукай, Мөслим, Минзәлә районнарындагы территориаль бүлегенә җибәрелә.

12. Шәһәр бәйрәм чаралары үткәрү урыннарында күчмә сәүдә объектларын урнаштыру Башкарма комитетның аның территориясендә бәйрәм чарасы үткәрелә торган тиешле район (Автозавод, Комсомол, Үзәк) хакимиятенең территориядәге оешмалар белән үзара эшчәнлек бүлеге белгечләре һәм Башкарма комитетның икътисадый үсеш һәм эшмәкәрләккә ярдәм күрсәтү идарәсенең кулланучылар базары бүлеге белгечләре белән берлектә башкарыла.

13. Күчмә сәүдә объектларын рөхсәтсез урнаштырырга рөхсәт ителми.

## 3. Күчмә сәүдәне үткәргәндә хуҗалык итүче субъектларга карата таләпләр

14. Күчмә сәүдә объектлары заманча эстетик зәвык таләпләренә җавап бирергә һәм чаралар башланганчы 1 сәгать алдан эшкә әзер булырга тиеш. Сәүдә урыны бәйрәмчә бизәлергә, оешманың фирма исеме, урнашу урыны, аның юридик адресы, шулай ук юридик затның исеме яисә шәхси эшмәкәрнең фамилиясе, исеме, атасының исеме (булганда) күрсәтелгән элмә такта булырга тиеш. Күчмә сәүдәдә катнашучылар сәүдә урынын чүп җыю өчен урналар белән тәэмин итәргә, чара үткәрү вакытында чүпне полиэтилен пакетларга җыеп, тәртип һәм чисталык сакларга тиеш. Эш тәмамлангач, янәшә территорияне җыештыруны һәм чүпләрне алып китүне тәэмин итәргә.

15. Товарлар сату түбәндәгеләр булганда гамәлгә ашырылырга тиеш:

1) сатучының фамилиясе, исеме, атасының исеме (булганда) күрсәтелгән шәхси карточкасы (бейджы);

2) сатучының шәхесен раслаучы паспорт яки башка документ күчермәсе;

3) сатучының күчмә сәүдәдә катнашучы белән хезмәт яки гражданлык-хокукый мөнәсәбәтләрен раслаучы документ;

4) сатыла торган товарга товар турында документлар;

5) сатыла торган товарларның сыйфатын һәм куркынычсызлыгын раслаучы документлар (шул исәптән яраклылык сертификатлары яки декларацияләре яисә аларның тиешле тәртиптә расланган күчермәләре, ветеринария таныклыклары, сыйфат таныклыклары);

6) медицина тикшерүе узу турында билге белән сатучының шәхси медицина кенәгәсе (азык-төлек товарлары сатканда, җәмәгать туклануы хезмәтләре күрсәткәндә);

7) санитар кием (халат, алъяпкыч, перчаткалар, баш киеме);

8) санитария кагыйдәләрен һәм шәхси гигиена кагыйдәләрен үтәү өчен шартлар (кулъюгыч, сабын, сөлге).

Күрсәтелгән документлар күчмә сәүдәдә товарлар сату (хезмәтләр күрсәтү) буенча эшчәнлекне гамәлгә ашыру дәвамында сатучыда сакланырга тиеш һәм алар Россия Федерациясе законнарында каралган очракларда күчмә сәүдәне оештыручының, контроль органнарының һәм сатып алучыларның таләбе буенча күрсәтелә.

16. Товарлар сатканда сатучы кулланучыларга товарлар һәм аларны җитештерүчеләр турында ачык һәм аңлаешлы итеп, товарны дөрес сайлау мөмкинлеген тәэмин итә торган тиешле һәм дөрес мәгълүматны җиткерергә бурычлы.

17. Күчмә сәүдәдә сатыла торган товарлар законда билгеләнгән тәртиптә эшләнгән бәя күрсәткечләре белән тәэмин ителергә тиеш.

18. Күчмә сәүдә үткәргәндә түбәндәгеләрне ваклап сату рөхсәт ителми:

- алкоголь продукциясе, сыра һәм сыра нигезендә җитештерелгән эчемлекләр;
- пыяла савыттагы эчемлекләр;
- тәмәке эшләнмәләре.

19. Азык-төлек товарларын ваклап сатуны һәм җәмәгать туклануы хезмәтләре күрсәтүне гамәлгә ашыра торган сәүдә урыннары җитәрлек санда товарлар кую өчен лотоклар, бер тапкыр кулланыла торган савыт-саба, төрү материалы, салфеткалар, ашъяулыклар белән тәэмин ителергә тиеш.

20. Күчмә сәүдәдә товарлар сату (хезмәтләр күрсәтү) буенча эшчәнлекне гамәлгә ашырганда катнашучыларның (сатучыларның) бурычлары:

1) халыкның санитар-эпидемиологик иминлеген, янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү өлкәсендә, әйләнә-тирә мохитне саклау, ветеринария өлкәсендә кулланучыларның хокукларын яклау турында Россия Федерациясе законнары таләпләрен үтәү;

2) аерым төр товарлар сатуга куела торган таләпләрне үтәү;

3) Россия Федерациясе законнарында каралган башка таләпләрне үтәү;

4) чисталык һәм тәртипне саклау, сәүдә урыны янындагы чүп җыю савытларының вакытында чистартылуын тәэмин итү;

5) предприятиенең профиле һәм махсуслашуы нигезендә азык-төлек продуктларының ассортимент исемлеген үтәү;

6) Россия Федерациясе законнарында каралган очракларда товарлар (хезмәтләр) өчен сатып алучылар белән исәп-хисапны контроль-касса машиналарын кулланып башкару;

7) чара тәмамланганнан соң, сәүдә урынын ике сәгать эчендә бушату.

21. Күчмә сәүдә объектын эксплуатацияләү кагыйдәләрен, эшне оештыру тәртибен үтәү өчен җаваплылык гамәлдәге законнар нигезендә күчмә сәүдә объектларын урнаштырган оешма җитәкчесенә; шәхси эшмәкәргә; «Һөнәри керемгә салым» махсус салым режимын кулланучы физик затка йөкләнә.

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә иҗтимагый-сәяси, массакүләм мәдәни һәм массакүләм спорт бәйрәм чаралары үткәргәндә сәүдә оештыру тәртибе турында нигезләмәгә
1 нче кушымта

_____елның «___»_____________
Яр Чаллы шәһәре территориясендә
күчмә сәүдә оештыру турында
хәбәр

Башкарма комитетның ________________________________________________________
(аның нигезендә шәһәр чарасы оештырыла торган муниципаль хокукый актның исеме, датасы, номеры)
_____________________________________________________________________________
үтәү йөзеннән, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты 20___ елның «___» _____________ Яр Чаллы шәһәре территориясендә күчмә сәүдә оештыру турында хәбәр итә.

Күчмә сәүдә 20___ елның «____» ___________ товарлар сату һәм хезмәтләр күрсәтү буенча эшчәнлекне гамәлгә ашыру өчен үткәрелә.

Үткәрү урыны: _____________________________________________________________
_____________________________________________________________________________

Күчмә сәүдәнең эш режимы ________ сәгатьтән ________ сәгатькә кадәр.

Күчмә сәүдәдә катнашучылар – Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә теркәлгән юридик затлар яки шәхси эшмәкәрләр, «Һөнәри керемгә салым» махсус салым режимын кулланучы физик затлар.

Заявкалар 20___ елның «_____» ___________________ башлап 20___ елның «_____» __________________ кадәр кабул ителә.

Товарлар сату һәм хезмәтләр күрсәтү буенча эшчәнлекне гамәлгә ашыру өчен сәүдә урыннары күчмә сәүдәдә катнашучыларга түләүсез бирелә.

Сәүдә урыны электр энергиясе белән җиһазландырылмаган.

Башкарма комитет Җитәкчесе исеменә заявка 20___ елның «___» ____________ кадәр Яр Чаллы шәһәре Башкарма комитетына kancel.chelny@tatar.ru электрон адресына, әлеге хәбәргә кушымтада каралган форма буенча, түбәндәге документларны теркәп җибәрелә:

- юридик затлар өчен – юридик зат турында мәгълүматларны бердәм дәүләт юридик затлар реестрына кертүне раслый торган документ күчермәсе;

- шәхси эшмәкәрләр өчен – шәхси эшмәкәр турында мәгълүматларны бердәм дәүләт шәхси эшмәкәрләр реестрына кертүне раслый торган документ һәм салым органында исәпкә кую турында таныклык күчермәсе;

- «Һөнәри керемгә салым» махсус салым режимын кулланучы физик зат өчен – физик затны һөнәри керемгә салым түләүче сыйфатында исәпкә кую турында белешмә күчермәсе.

Заявкалар күчмә сәүдәдә катнашуга заявкаларны карап тикшерү буенча комиссия тарафыннан карап тикшерелә.

Комиссия сәүдә урыны бирү һәм күчмә сәүдәдә катнашучылар исемлегенә кертү турында яисә сәүдә урыны бирүдән баш тарту турында карар кабул итә.

Күчмә сәүдәдә катнашучыларга таләпләр

1. Күчмә сәүдә объектлары заманча эстетик зәвык таләпләренә җавап бирергә һәм чаралар башланганчы 1 сәгать алдан эшкә әзер булырга тиеш. Сәүдә урыны бәйрәмчә бизәлергә, оешманың фирма исеме, урнашу урыны, аның юридик адресы, шулай ук юридик затның исеме яисә шәхси эшмәкәрнең фамилиясе, исеме, атасының исеме (булганда) күрсәтелгән элмә такта булырга тиеш. Күчмә сәүдәдә катнашучылар сәүдә урынын чүп җыю өчен урналар белән тәэмин итәргә, чара үткәрү вакытында чүпне полиэтилен пакетларга җыеп, тәртип һәм чисталык сакларга тиеш. Эш тәмамлангач, территорияне җыештыруны һәм чүпләрне алып китүне тәэмин итәргә.

2. Товарлар сату түбәндәгеләр булганда гамәлгә ашырылырга тиеш:

1) сатучының фамилиясе, исеме, атасының исеме (булганда) күрсәтелгән шәхси карточкасы (бейджы);

2) сатучының шәхесен раслаучы паспорт яки башка документ күчермәсе;

3) сатучының күчмә сәүдәдә катнашучы белән хезмәт яки гражданлык-хокукый мөнәсәбәтләрен раслаучы документ;

4) сатыла торган товарга товар турында товар документлары;

5) сатыла торган товарларның сыйфатын һәм куркынычсызлыгын раслаучы документлар (шул исәптән яраклылык сертификатлары яки декларацияләре яисә аларның тиешле тәртиптә расланган күчермәләре, ветеринария таныклыклары, сыйфат таныклыклары);

6) медицина тикшерүе узу турында билге белән сатучының шәхси медицина кенәгәсе (азык-төлек товарлары сатканда, җәмәгать туклануы хезмәтләре күрсәткәндә);

7) санитар кием (халат, алъяпкыч, перчаткалар, баш киеме);

8) санитария кагыйдәләрен һәм шәхси гигиена кагыйдәләрен үтәү өчен шартлар (кулъюгыч, сабын, сөлге).

Күрсәтелгән документлар күчмә бәйрәм сәүдәсендә товарлар сату (хезмәтләр күрсәтү) буенча эшчәнлекне гамәлгә ашыру дәвамында сатучыда сакланырга тиеш һәм алар Россия Федерациясе законнарында каралган очракларда күчмә сәүдәне оештыручының, контроль органнарының һәм сатып алучыларның таләбе буенча күрсәтелә.

3. Товарлар сатканда сатучы кулланучыларга товарлар һәм аларны җитештерүчеләр турында ачык һәм аңлаешлы итеп, товарны дөрес сайлау мөмкинлеген тәэмин итә торган тиешле һәм дөрес мәгълүматны үз вакытында җиткерергә бурычлы.

4. Күчмә сәүдәдә сатыла торган товарлар законда билгеләнгән тәртиптә эшләнгән бәя күрсәткечләре белән тәэмин ителергә тиеш.

5. Түбәндәгеләрне ваклап сату рөхсәт ителми:

- алкоголь продукциясе, сыра һәм сыра нигезендә ясалган эчемлекләр;
- пыяла савыттагы эчемлекләр;
- тәмәке эшләнмәләре.

6. Җәмәгать туклануы һәм ваклап азык-төлек товарлары сату объектлары җитәрлек санда товарлар кую өчен лотоклар, бер тапкыр кулланыла торган савыт-саба, төрү материалы, салфеткалар, ашъяулыклар белән тәэмин ителергә тиеш.

7. Күчмә сәүдәдә товарлар сату (хезмәтләр күрсәтү) буенча эшчәнлекне гамәлгә ашырганда катнашучыларның (сатучыларның) бурычлары:

1) халыкның санитар-эпидемиологик иминлеген, янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү өлкәсендә, әйләнә-тирә мохитне саклау, ветеринария өлкәсендә кулланучыларның хокукларын яклау турында Россия Федерациясе законнары таләпләрен үтәү;

2) аерым төр товарлар сатуга куела торган таләпләрне үтәү;

3) Россия Федерациясе законнарында каралган башка таләпләрне үтәү;

4) чисталык һәм тәртипне саклау, сәүдә урыны янындагы чүп җыю савытларының вакытында чистартылуын тәэмин итү;

5) предприятиенең профиле һәм махсуслашуы нигезендә азык-төлек продуктлары ассортименты исемлеген үтәү;

6) Россия Федерациясе законнарында каралган очракларда товарлар (хезмәтләр) өчен сатып алучылар белән исәп-хисапны контроль-касса машиналарын кулланып башкару;

7) чара тәмамланганнан соң ике сәгать эчендә сәүдә урынын бушату.

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә иҗтимагый-сәяси, массакүләм мәдәни һәм массакүләм спорт бәйрәм чаралары үткәргәндә сәүдә оештыру тәртибе турында нигезләмәгә
2 нче кушымта

Күчмә сәүдәдә катнашуга заявкаларны карап тикшерү буенча комиссия составы

| Ф.И.А.и. | Вазыйфа |
|---|---|
| Кропотова Н.А | комиссия рәисе, Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары |
| Солтанова Р.К. | комиссия секретаре, Башкарма комитетның икътисадый үсеш һәм эшмәкәрләккә ярдәм күрсәтү идарәсенең кулланучылар базары бүлеге башлыгы |
| комиссия әгъзалары: | |
| Гыйләҗева Г.В. | комиссия рәисе урынбасары, Башкарма комитетның икътисадый үсеш һәм эшмәкәрләккә ярдәм күрсәтү идарәсе башлыгы |
| Кәрамиев Р.Р. | Башкарма комитетның мәдәният идарәсе башлыгы |
| Нәҗметдинов А.Х. | Башкарма комитет Үзәк районы хакимиятенең территориядәге оешмалар белән үзара эшчәнлек бүлеге башлыгы |
| Нуруллина А.С. | Башкарма комитет Комсомол районы хакимиятенең территориядәге оешмалар белән үзара эшчәнлек бүлеге башлыгы |
| Хөснуллин А.Ш. | Башкарма комитет Автозавод районы хакимиятенең территориядәге оешмалар белән үзара эшчәнлек бүлеге башлыгы |
| Чураева Л.Г. | Башкарма комитетның икътисадый үсеш һәм эшмәкәрләккә ярдәм күрсәтү идарәсе кулланучылар базары бүлегенең баш белгече |

20__елның «___» ________
күчмә сәүдә оештыру
турындагы хәбәргә
кушымта

Яр Чаллы шәһәре
Башкарма комитеты Җитәкчесе
Ф.Ш. Салаховка

________________________________________
(юридик затның исеме, оештыру-хокукый формасы, шәхси эшмәкәрнең,
үзмәшгульнең фамилиясе, исеме, атасының исеме)

________________________________________
(урнашу урыны, яшәү урыны)

________________________________________
(ИНН)

________________________________________
(җәмәгать тукланагы яки сәүдә предприятиесе төре)

________________________________________
элемтә телефоннары

20___ елның «___» __________
___________________________ үткәргәндә
күчмә сәүдәдә катнашуга
ЗАЯВКА

Күчмә сәүдәдә катнашучылар исемлегенә кертүегезне һәм
________________________________________
________________________________________
хезмәтләр күрсәтү өчен,
________________________________________
сату өчен сәүдә урыны (үлчәме кв.м.) (кирәкле саны) бирүегезне сорыйм.
Сатыла торган товарлар ассортименты, күрсәтелә торган хезмәтләр исемлеге:
________________________________________
________________________________________
Куркынычсыз хезмәтләр күрсәтү өчен җаваплы (Ф.И.А.и., телефоны) ____________
________________________________________
Товарлар сатуны (хезмәтләр күрсәтүне) оештыруга таләпләр белән таныштым.

Имза Дата

МУ

Заявкага терким (кирәклесенең атына сызарга):
- юридик зат өчен – юридик зат турында мәгълүматларны бердәм дәүләт юридик затлар реестрына кертүне раслый торган документ күчермәсе;
- шәхси эшмәкәр өчен – шәхси эшмәкәр турында мәгълүматларны бердәм дәүләт шәхси эшмәкәрләр реестрына кертүне раслый торган документ, салым органында исәпкә кую турында таныклык күчермәсе;
- үзмәшгуль өчен – физик затны һөнәри керемгә салым түләүче сыйфатында исәпкә кую турында белешмә күчермәсе

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә иҗтимагый-сәяси, массакүләм мәдәни һәм массакүләм спорт бәйрәм чаралары үткәргәндә сәүдә оештыру тәртибе турында нигезләмәгә
3 нче кушымта

РАСЛЫЙМ
Башкарма комитет
Җитәкчесе

_____________Ф.Ш. Салахов
«____» ___________ 20____

_______________________________________________________

күчмә сәүдә хезмәте күрсәтүдә катнашучы оешмаларның, шәхси эшмәкәрләрнең, «Һөнәри керемгә салым» махсус салым режимын кулланучы физик затларның исемлеге

Сәүдә урыны: _________________

Сәүдә датасы һәм вакыты: 20__ елның «___» ________ ___ сәгатьтән ___ сәгатькә кадәр.

| № т/б | Оешманың (шәхси эшмәкәрнең, үзмәшгульнең) исеме | Махсуслашуы | Сәүдә урыннарының саны |
|---|---|---|---|